ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.09.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**2208**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзү белән бәйле, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2004 елның 30 декабрендәге «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 214-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 2462 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны төзү белән бәйле, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ регламентына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының16.10.2019 ел, №2181, 20.03.2020 ел, №574, 14.12.2020 ел, №2436 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Административ регламент), Административ регламентның 1.7 пунктындагы тугызынчы абзацын яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә :

«Россия Федерациясе Үзәк банкыннан төзүче белән поручительлек килешүе төзелгән банкның яисә «Россия Федерациясендә иминият эшен оештыру турында» 27.11.1992 ел, №4015-1 Россия Федерациясе Законы нигезендә, Россия Федерациясе территориясендә иминият эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шулай ук гражданнарның һәм юридик затларның 214-ФЗ номерлы Федераль законны бозуга бәйле шикаятьләрен карау хокукына ия булган, төзүче тарафыннан иминият

килешүе № 214-ФЗ Федераль закон таләпләре буенча төзелгән иминият оешмасының яисә чит ил иминият оешмасының туры килүе турында мәгълүмат соратып алырга».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында ( http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев